КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 июль г.Казань № 805

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына грант ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 14 июль, 572 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына грант ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 14 июль, 572 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 октябрь, 1013 нче; 2022 ел, 11 май, 428 нче; 2022 ел, 10 сентябрь, 976 нчы; 2023 ел, 20 апрель, 5 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Кече эшмәкәрлек субъектларын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган «Агропрогресс» грантларын бирү тәртибенең 1.4 пунктында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Гаилә фермаларын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган грантлар бирү тәртибенең 1.4 пунктында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган хуҗалыклар төзү һәм (яки) аларны үстерү проектларын гамәлгә ашыруга бәйле «Агростартап» грантларын бирү тәртибенең 1.4 пунктында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин